*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА
**БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [**ө**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Төлке тиресе белән, былбыл өне белән кадерле.* (Мәкаль)
а) 2
ә) 3
б) 4
в) 5

2. Җөмләдәге ябык иҗекләр санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Булыр-булмас эшне алдан шаулап йөрергә кирәкмәс*. (Мәкаль)
а) 8
ә) 9
б) 10
в) 12

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
***ут борчасы***
а) мактанчык
ә) бик тере, хәрәкәтчән
б) бик ачулы
в) бик булдыклы

4. Алынма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
а) эшләпә
ә) яулык
б) күлмәк
в) итәк

5. Җөмләдәге тамыр сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Җәяүле атлыга юлдаш булмый*. (Мәкаль)
а) җәяүле
ә) атлыга
б) юлдаш

в) булмый

6. Күрсәтү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
а) күпме
ә) сезнеке
б) шунда
в) ниндидер

7. Затланышсыз фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) барса
ә) барырга
б) бар
в) бардык

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**
*Туры **юлдан** олы юл яхшы.* (Мәкаль)
а) тәмамлык
ә) урын хәле
б) рәвеш хәле
в) шарт хәле

9. Раслауны белдерә торган кереш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
а) димәк
ә) беренчедән
б) бәхеткә
в) һичшиксез

10. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Ун адәм салган күперне бер адәм бозар*. (Мәкаль)
а) аналитик иярчен аергыч җөмлә
ә) синтетик иярчен аергыч җөмлә
б) синтетик иярчен урын җөмлә
в) синтетик иярчен тәмамлык җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

_____________ ассимиляция язуда чагылыш таба. Татар телендә _____________ ачык иҗек бар. Синонимик ояда иң еш кулланыла торган _____________ сүз була. _____________ санының саналмышы булмый. Исем фигыль – _____________ фигыль. -ның/-нең кушымчалы сүз җөмләдә фигыльгә иярсә, ул _____________ була. Раслау һәм _____________ җөмләләр була. Иртүче теркәгечләр һәрвакыт _____________ җөмләдә килә.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Сүзләрне дөрес итеп урнаштырып, ике мәкаль языгыз. **(4 балл)**

*түбән, үзе, кеше, үз, уйлама, һичкемне, кадерен, үзеңнән, арттырыр*

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Хуже нет для полевых и лесных зверьков, чем малоснежное начало зимы! Голая земля промерзает все глубже, становится твёрдой, как камень.

Но вот повалил снег. Сухое снежное море покрывает землю. На дне снежного моря теплее, чем на его поверхности. Сюда не попадает леденящий ветер. *(В.Бианки)*

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ИКЕ ФӘЛСӘФӘ

**Яшь кешенең фәлсәфәсе шундый:**
**Бәхет эзләр офыклардан ары.**
Сүзсез генә яшен коеп торыр
Бакча артындагы тупыллары.

Карт кешенең фәлсәфәсе башка:
Туган якка юлы, туган якка.
Моңаешып калган тупыллары
Ничә еллар буе шунда тарта?

Туган яктан күңел бизәме соң?
Җырлары да моңлы, сагынганга.
Мөлдерәшеп, күз яшьләре тама,
Тупылларга килеп кагылганда.

(*Фәйрүзә Мөслимова*)

2.1. Беренче куплеттагы сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл)** ________________________

______________________________________________________________

2.2. Кече тел ассимиляциясе күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)**

______________________________________________________________

2.3. Икенче куплеттагы алынма сүзләрне языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________

2.4. ***Офык*** сүзенең синонимын языгыз. **(1 балл) ________________________**

2.5. Икенче куплеттагы затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________

2.6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: баш кисәкләрнең астына сызыгыз, компонент чикләрен билгеләгез, схема сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(4 балл)**

3. ***“Туган ягым һәм минем киләчәгем”*** дигән темага 10-12 җөмләдән торган инша языгыз. **(15 балл)**